ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

04.02.2021 с. Верхний Услон 102

«Югары Ослан муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2013нче елның 9нчы сентябрендәге 1354нче номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, 2020нче елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының көтелгән үтәлеше йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021нче елның 4нче гыйнварындагы ПР-3 номерлы беркетмәсен үтәү йөзеннән, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Югары Ослан муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2013нче елның 9нчы сентябрендәге 1354нче номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертергә, - 1нче бүлеккә түбәндәге эчтәлекле пункт өстәргә:
«1.7. Социаль ярдәм чаралары алучы мөрәҗәгать итүчеләрнең салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясенең Салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле бурычы булмаска тиеш.»;
- 2 нче бүлекнең 2.1нче пунктына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

«ll) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә".

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшеп торуны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитеты җитәкчесе И. И. Шакиров